| | |
|---|---|
| СОВЕТ БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |

с. Большие Меми

24.09.2018 № 45-206

Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча
җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п. нигезендә Олы Мәми авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2018 елның 20 сентябрендәге 44-203 номерлы Олы Мәми авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» Олы Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 20 сентябрендәге 13 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Олы Мәми авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Олы Мәми авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

"2019 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия һәр авыл җирлегендә яшәүче һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә риза булырсызмы?:

- Олы Мәми авылында Яшьләр һәм Елга аръягы урамнарына өлешчә вак таш түшәү;

-Заборная Поляна авылында урамнарны яктырту системасын ремонтлау

ӘЙЕ ЮК

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары

Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Олы Мәми авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Олы Меми авыл җирлеге башлыгы Г.А. Фомина